**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 25 марты** **№ 251**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 28 декабрь 23 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2005 елның 28 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә, 17 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез идарәдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешманың сайланулы органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездда (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г)идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен оешманы гамәлгә куючының муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, Попечительләр яки Күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә хакы юк».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**муниципаль район**
**Советы Рәисе** **Н. А. Вазыйхов**